**Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләрендәге**

**11 нче сыйныф укучылары өчен татар теле һәм әдәбиятыннан**

**IVХалыкара олимпиада биремнәре**

1. Т.Миңнуллинның “Әлдермештән Әлмәндәр” драмасында автор позициясен ачыклагыз, сез автор фикере белән килешәсезме? Әлеге әсәр татар драматургиясенә нинди яңалыклар алып килә? Үз фикерегезне дәлилләп языгыз (20 балл).
2. Муса Җәлил иҗатына хас нинди сыйфатларны билгели аласыз? Аның шигырьләре бүгенге көндә дә актуальме, булса, кайсы яктан дип уйлыйсыз? (20 балл)
3. *Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы, / Шат яратса да, җиһанга ят яраткан раббысы*. (Г.Тукай). Әлеге шигырь юлларына таянып, 150 сүздән дә ким булмаган күләмдә инша языгыз (20 балл).
4. Түбәндә тәкъдим ителгән аңлатмаларга нигезләнеп һәм җавап өлешендә күрсәтелгән сүзне истә тотып, туры килә торган фразеологик әйтелмәләрне языгыз. (Һәр дөрес җавап - 2 балл; барлыгы 10 балл).

*1) аерылмас дуслар*

________________*җил дә*__________________________________

*2) акрын, салмак килүче*

*адымын* _______________________________________________

*3) аз гына бер җирен яхшыртам дип, эшләнгән эшне бозып кую*

________*төзәтәм дип*_____________________________________

*4) беркайчан үтәлмәячәк коры вәгъдәләр*

_______________*кар*_____________________________________

*5) бик тиз арада*

______________*ачып*_____________________________________

5. Түбәндә бирелгән сүзтезмәләрдәге бертөрле сүзләрне, мәгънәләренә карап, ике төркемгә аерыгыз. Омоним пар булган очракта янына омоним дип, күп мәгънәле сүзләр булганда, күп мәгънәле дип языгыз. (Һәр дөрес җавап - 1 балл; барлыгы 5 балл).

*1) бармак бите – дәфтәр бите* ____________

*2) ата күркә – нарат күркәсе* _______________

*3) болыт елавы – кызлар елавы*_______________

*4) авырудан сызу – таблица сызу*_______________

5) *Өй түбәсе – баш түбәсе* __________________

6. Боерык фигыльгә аңлатма бирегез. Боерык фигыльнең төрле мәгънәләр белдерә алуын мисаллар белән дәлилләгез. (10 балл)

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

_______________________________________________________________

7 . Өзекне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез (Һәр бирем - 3 балл; барлыгы 15 балл).

*1) Көтмәгәндә, күп юудан агарып беткән гимнастеркасына өч Дан ордены таккан фронтовик карт белән таныштым. 2) Һәрвакыт ачык, көлеп-елмаеп торучы бу кеше сүзгә дә бик һәвәс икән. 3) Кыска гына вакыт эчендә ул миңа үзенең бөтен фронт эпопеясен сөйләп чыгарга да, сугыш кырында очраган мәзәк хәлләрне күздән кичерергә дә өлгерде. 4) Мин сизендем <...> ул үзе күргән фронт тормышының иң җиңел, якты минутларын гына сөйли, күңеле төпкелендә яткан авыр, газаплы хатирәләренә кагылмаска тырыша иде.*

*5) Ә мин бу көнне бик кыю идем. 6) Уйлап та тормыйча, карт ветеранның сугыш юлларында тап булган иң истәлекле хатирәсе хакында сорадым. 7) Әңгәмәдәшем шунда ук уйчанланып, басылып калды, әмма бу сорау аның өчен бөтенләй үк көтелмәгән түгел иде. (Г. Гыйльманов)*

1. 4 нче җөмләдә <...> тамгасы урынына куелырга тиешле тыныш билгесен языгыз.

______________________________________________________________________

2. Өзектән *оста* сүзенең синонимын  язып алыгыз.

______________________________________________________________________

3. Өзектән парлы сүзне табып язып алыгыз.

______________________________________________________________________

4. Өзектәге кушма җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә языгыз.

______________________________________________________________________

5. Рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләр кулланылган җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә языгыз.

______________________________________________________________________